ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ютазинская, д.14А,

с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ютазы урамы, 14А йорт,

Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 2-44-12, факс:2-44-13, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 8 «21» май 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 22 июлендәге «Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 8 санлы карарын гамәлдән чыгару турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты арасында вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы 2022 елның 21 мартындагы килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең 2021 елның 22 июлендәге «Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 8 санлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина